*Муниципаль тур*

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2023-2024 нче уку елы**
**5 нче сыйныф**

**Максималь балл – 54**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **1** | **1** | **1** | **3** | **2** | **3** | **3** | **2** | **1** |

## II. Теоретик бирем.

Синонимнар турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**5 балл**)
Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III/.Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Җөмләләр һәм сүзлекләрне тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) Матур – ямьсез. | 1) Аңлатмалы сүзлек |
| Ә) Даруханә – аптека. | 2) Татарча – русча сүзлек |
| Б) Давыл, өермә, гарасат. | 3) Русча – татарча сүзлек |
| В) Окно – тәрәзә. | 4) Антонимнар сүзлеге |
| Г) Кунак – махсус чакырылган яисә күрешү өчен читтән килгән кеше. | 5) Синонимнар сүзлеге |

**Җавап : 42531**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Койма (**тактасына** / өстенә / баганасына) сары буяу белән буяп ясалган Кояш күк йөзендәге кара-кучкыл болытларга дәште:

- Әй, болытлар, күрәсезме мине? Мин – Кояш! Мин кояшларның да кояшы!

Коймадагы Кояш бөтерелә-бөтерелә чыркылдаган Чыпчыкка дәште:

- Әй, чыркылдык, күрәсеңме мине? Мин – Кояш! Кара миңа, (гаҗәплән / **соклан** / уйлан)! Миңа һәр кеше сокланып карый.

Кара-кучкыл болытларга коймадагы кояшның шулай әрсезләнеп (әйтүе / **шапырынуы** / кычкыруы) ошамады. Алар шыбыр-шыбыр яңгыр яудыра башладылар. “Бу – мин... мин...” – дип бытылдаган Кояшны яңгыр тамчылары коймадан ( бер сәгатьтә / **күз ачып йомганчы** / көн дәвамында) юып төшерде. (*Н. Каштаннан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

| | |
|---|---|
| Офыклар чал, болытлар чал, | Бозваткычсыз җибәрми боз |
| Чал диңгез яры. | Корабны ярга. |
| Күтә безне карлы-бозл... | Туза карлар, бозваткычлар |
| Төньяк причалы. | Безгә юл яра. (*Ф. Тарханова*) |

3. Шигырьдән рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(4 балл)**

**Төньяк, причал**

---

4. *Җибәрми* сүзен мәгънәви кисәкләргә таркатыгыз, нинди сүз төркеменә каравын, төрләнешен билгеләгез. **(4 балл)**

Җибәр – тамыр фигыль, -ми – юклык күрсәткече, модаль кушымча. Нигезе – җибәр-. Бу – хәзерге заман хикәя фигыль, юклыкта, 3 зат, берлек санда

5. “Яраткан китабым” темасына 7-8 җөмләдән торган инша языгыз. (**8 балл**)